В 1988–1990 гг. среди татар начали складываться различные неформальные группы и объединения. Постепенно они становились катализаторами общественного сознания; так формировалось татарское национальное движение. 27 июня 1988 года образовалось ядро Татарского общественного центра (ТОЦ), которое переросло в крупную организацию с программой общетатарского характера. В 1990 году образовались со своими программами и уставами: Комитет

“Суверенитет”, Союз молодежи “Азатлык”, Татарская партия независимости “Иттифак”, Молодежный центр исламской культуры “Иман”. 31 марта 1991 года была учреждена Исламская демократическая партия Татарстана.

9 октября 1992 года в г.Казани Татарский общественный центр провел съезд работников народного образования, где оформилась Всетатарская ассоциация “Магариф”.

В 1992 году в Татарстане функционировало свыше 60 общественных объединений различного типа (общественно-политические, религиозные, культурологические, экологические и т.д.) и разной ориентации, главной целью которых являлось объединение татар, живущих в различных регионах и странах.

Идеология русского национального движения в республике не получила заметного развития. Лишь общество “Славянский клуб” (1991г.) декларировало этнические приоритеты.

Идеей возрождения национальной образовательно- воспитательной системы, пробуждения национального самосознания, возрождения роли этноса, сохранения татарского языка пронизаны программные документы этих организаций. Во всех программных документах, резолюциях съездов и пленумов прослеживается постоянное внимание подрастающему поколению, молодежи, системе народного образования и подготовке педагогических кадров.

Татарский общественный центр систему образования и воспитания рассматривает как единую систему непрерывного образования, начиная с семейного воспитания и кончая высшим учебным заведением. В его программе говорится о необходимости создания материальных условий для полноценного воспитания детей в семье; повышения социального статуса матери, приравнивания ее воспитательных функций к любой другой работе в пользу общества; а также необходимости особых привилегий для дошкольных учреждений.

Идеи Союза татарской молодежи “Азатлык” созвучны с идеями Татарского общественного центра в области систе-

мы образования и педагогического наследия. Так же, как и ТОЦ, возрождение национальной системы образования Союз видит в повышении статуса татарского языка. На первом же съезде (13 октября 1990 г.) была принята резолюция об образовании и культуре, где предложено провести реорганизацию структуры органов просвещения и дошкольных учреждений с целью создания единой системы непрерывного образования на татарском языке; разработать концепцию татарской национальной школы с учетом многовекового опыта ее развития.

Общественная организация “Молодежный центр исламской культуры “Иман” в основном ориентируется на религиозную деятельность и выступает в большей мере за возрождение мусульманского наследия: ислам призван вернуть народу веру в духовные ценности и на их основе воспитывать новое поколение. (Этой идеологии соответствует принятое организацией 23 ноября 1991 года на II меджлисе обращение в Министерство просвещения ТССР о необходимости пересмотра учебных программ и введения изучения ислама в учебных заведениях всех уровней.)

Всетатарская ассоциация “Магариф”, как указывает само название, призвана способствовать совершенствованию системы народного образования. Программа ассоциации начинается с концепции развития татарского просвещения, которая состоит из 12 разделов. В Концепции рассматриваются вопросы, касающиеся всех звеньев национального образования; отводится огромная роль национальным традициям: только основываясь на положительных национальных традициях народа, школа может полностью выполнить свои воспитательные и образовательные функции. Наряду с современным образованием, национальная школа создаст условия для интеллектуального развития и формирования каждого ребенка как личности.

Во всех программных документах рассмотренных общественных организаций красной нитью проходит идея суверенитета республики, поддержка Декларации о суверените-

те Татарстана, принятой Верховным Советом Республики Татарстан 30 августа 1990 года и ознаменовавшей начало новой эпохи в истории татарского народа. Декларация и Конституция Республики Татарстан открыли широкие возможности самостоятельного решения вопросов развития культуры и образования.

*Гыйлаҗев Т.Ш.*, филол.фән.канд.

**20-30 нчы еллар тәнкыйтендә әдәби мирас мәсьәләсе**

20-30 нчы еллар әдәби тәнкыйть үткән юлда каршылыклы, катлаулы һәм, әйтергә кирәк, шактый буталчык дәвер булып тора. Әдәби мираска мөнәсәбәт мәсәләсе бу чор әдәби тәнкыйтендә бөтен зурлыгы белән куела. Совет әдәбият белемендә билгеле бер караш урнашканчы, бу мәсьәләгә каршылыклы, булталчык юл үтәргә туры килә. Ул совет властеның беренче елларында язылган мәкаләләрдә үк кузгатыла.

Аерым алганда, Г.Ибраһимов бу өлкәдә актив эшчәнлек күрсәтә. Ул, мәсәлән, 1920 елда язылган “Дүртенче елга кергәндә” исемле мәкаләсендә үк әдәбиятка “буржуазный яки пролетарский”[6] дип үлчәү сала. Шушы мәкаләдән күренгәнчә, матур әдәбият ике сыйныф – буржуазия һәм пролетариат үлчәвенә салына. Г.Ибраһимовның фикерләрен Г.Нигъмәти, Г.Гали, Ф.Сәйфи-Казанлы, Г.Сәгъди кебек галимнәр алга таба үстерә, гамәли яктан тормышка ашыра башлыйлар. Ә үз иҗатларында әдәби кануннар, эстетик категорияләр белән эш итүче Г.Гобәйдуллин, Җ.Вәлиди, Г.Рәхимнәрнең каләмнәре тынып тора. Әмма Г.Ибраһимовның Рәшит Ибраһимов вафат булу* уңаеннан язылган “Тарихи кыңгыравык өзелде”[5] дигән мәкаләсе Җ.Вәлидине кулына каләм алырга мәҗбүр итә. Әдәби мирас, классик әдәбиятка мөнәсәбәт мәсьәләсендә Октябрьгә кадәрге

---

* Рәшит Ибраһимовның 1922 елдавафат булуы ялгыш хәбәр булып чыга. Соңгы мәгълүматларга караганда, ул 1944 елда гына үлә.

әдәби тәнкыйтьтә ат уйнаткан ике зур, талантлы шәхес арасында фикер көрәше башлана. Аның җитдилеген тоеп, Җ.Вәлиди: "Бу татар әдәбиятының хәят вә мәмәт мәсьәләсе"[2], -дип язып чыга.

Г.Ибраһимов бу мәкаләсендә, матур әдәбиятны үз үлчәвенә салып, әдәби мирасны "тарихи бер дәвернең тарихи материаллары уларак"[5] карый. Г.Ибраһимов әдәби мирасның идея-эстетик байлыгын, гомумкешелек кыйммәтен инкарь итү юлына баса. Мәсьәләне берьяклы, бары тик социологик планда гына чишәргә омтыла. Әдәби әсәрнең кыйммәтен инкыйлаби көрәш вакыйгалары, эшче-крестьян тормышы, көнүзәгендәге актуаль мәсьәләләр яктыртылышы ноктасыннан бәяли. Әдәбиятчы галим сүз сәнгатенең сыйнфыйлыгын абсолютлаштыра. Җ.Вәлиди, Г.Ибраһимовның матур әдәбият үсеше, яшәеше өчен никадәр хәвефле сүзләр, фикерләр белән чыгыш ясавын тоеп, әдәби мираска мондый карашның хаксызлыгын расларга тырыша, бөтенесен бер үлчәүгә салуны шаблончылык[3] дип атый. Ике чор әдәбиятын бер-берсенә каршы куюның нигезсезлеген күрсәтә.

Бәхәстә ике як тарафыннан 7 мәкалә язылa. Шунысы кызыклы: фикер көрәше, бәхәс бүгенге көндә укучыларга әйләнеп кайткан Г.Исхакый мирасы тирәсендә дә бара. "Аларның ("Тормышмы бу?", "Мулла бабай", "Сөннәтче бабай" – Г.Т.) әдәби кыйммәтләре дә шунда һәм аларның бер дәвердә мәгънәле булып та, икенче дәвердә мәгънәсез булулары мөмкин түгел"[3], - дип, тәнкыйтьче тормышны дөрес чагылдырган, художестволы дөреслеккә ия булып, гомумкешелек мәсьәләләр күтәргән әдәбиятның, чорлар, карашлар үзгәргәнгә карап, үз эстетик кыйммәтен югалтмавын күрсәтә. Әмма Җ.Вәлиди сүзләре белән әйтсәк, "бу чепчи әдәби бәхәс", "милләтлелек, коммунистлык, яки консерваторлык, революционерлык вә гомумән сәяси караш почвасына тартыла".[3] Җ.Вәлиди белән Г.Ибраһимов арасындагы бәхәстә өстенлек икенчесе ягында кала. Әдәби тәнкыйтьнең шушы чорында ук художестволы әдәбиятның сәнгать критерийлары сәяси критерийлар белән алыштырыла башлый. Нәфис әдәбиятның

сәясәт белән кушылуына җирлек әзерләнә.

Әдәбиятның сыйнфыйлыгы һәм өстән төшерелгән партиялелек принцибы үзләштерелә барган саен, XX йөз башы әдипләре иҗатына һөҗүмнәр көчәя бара. Классик әдәбиятның идея эчтәлегенә, күтәрелгән мәсьәләләренә, стиленә, иҗат методына ревизия ясала башлый. 20–30 нчы еллар тәнкыйте XX гасыр башы әдәбиятын, чор әдәбиятына каршы куеп, марксистик-ленинчыл идеология позициясеннән торып тикшерә. Әдәби тәнкыйть, иң беренче нәүбәттә, классик әдәбиятның миллилегенә, халыкчылыгына һәм dини-әхлакый характерына каршы аяусыз көрәш башлый. Мондый мөнәсәбәт Г.Тукай, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан һ.б.ларның иҗатларын бәяләүдә урын ала.

Без өйрәнә торган дәвер тәнкыйди фикеренең Г.Тукай иҗатына бәясе үзенчәлекле һәм катлаулы булды. Бу эшкә Г. Сәгъди, Ф.Бурнаш, Г.Гали, Г.Нигъмәти, Ф.Сәйфи-Казанлы һәм башкалар алына. Әдәбият галимнәрен һәм тәнкыйтьчеләрне, иң беренче чиратта, шагыйрь иҗатының иҗтимагый-сәяси йөзе, сыйнфый ягы кызыксындыра, һәр тәнкыйтьче диярлек үз анализын Тукай поэзиясендә дини мотивларны тикшерүдән башлый. Аның шигъриятендәге дини-әхлакый әдәбияттан, Коръәннән килә торган традицияләрне Тукайның ислам диненә мөнәсәбәтен бәяләүдә әдәби тәнкыйть бер чиктән икенче чиккә ташлана. Мәсәлән, Ф.Бурнаш шагыйрьнең шигырьләр җыентыгына язылган кереш мәкаләсендә Тукайның атеистик карашлары турында сүз алып бара.[1] Ул бу нәтиҗәне Г. Тукайның бары тик иске карашлы, надан дин әһелләренә, ислам динен яхшы аңламаган. Коръән белән гамәл кылмаган муллаларга, ишаннарга, мөритләргә каршы юнәлтелгән шигырьләренә таянып ясый һәм, әйтергә кирәк, дөреслектән ерак тора. Г.Гали, Ф.Сәйфи-Казанлы, Г. Сәгъдиләр, киресенчә, шагыйрьне динчелектә, “динне милләткә бәйләп йөрү”дә гаепләп чыгалар. Аерым алганда, Г.Гали Фатих Сәйфи-Казанлы төзегән Г. Тукайның академик томлыклары дөнья күргәч язган “Академик нәшерләрдә гыйльми нигезләр” дигән мәкаләсендә шагыйрь

шигъриятенә түбәндәгечә бәя бирә: “Тукай шәп шагыйрь, ләкин ул динче, ул милләтче, ул романтик шагыйрь”.[4] Болар - шагыйрь иҗатына ташланган зур гаеп, олы кимчелекләр. Егерменче еллар ахырында күп әдипләр иҗаты милләтчелектә гаепләнә. Миллилек Г.Ибраһимовның “Пролетариат әдәбияты турында” дигән хезмәтендә пролетариат әдәбиятының төп үзенчәлекләреннән берсе буларак күрсәтелгән интернационализмга каршы куела. Мәгълүм булганча, сәнгатьчә фикерләүнең романтик төренә чор тәнкыйтенең мөнәсәбәте катлаулы була. Ул татар совет әдәбияты өчен “чит, ят, консерватив” ысул буларак карала. Аңа вульгар социологик караш урнаша: идеализм белән бәйләп тикшерелә башлый. Димәк, Тукай иҗатында күзәтелгән романтизм да аның мирасының зур җитешсезлеге буларак ассызыклана. Шуңа күрә Г.Гали, Тукай әсәрләрен яңа чор укучыларына тәкъдим иткәндә, “аның менә бу якларын кызганычсыз рәвештә ачып бирергә. Тукай иҗатының социаль йөзен ачык күрсәтеп, бөтен пәрдәләрне марксизм кайчысы белән кисеп бирергә”[4] чакыра.

Утызынчы елларда Г. Тукай лирикасына әдәби тәнкыйтьнең мөнәсәбәте беркадәр уңай якка үзгәрә, аны социаль яктан реабилитацияләү башлана. Мондый төсмер тәнкыйтькә яңа килгән Х.Туфан,[11] Ф.Хөсни[12] мәкаләләрендә күренә: “...буржуаз милләтчеләр һәм иске әдәбиятны, шулай ук пролетариатның үз әдәбиятын да... эшче крестьяннардан яшерергә, ул әсәрләрне тудыручы язучылар өстенә тап ташларга маташтылар. Халык шагыйре мәрхүм Г.Тукай әсәрләре моңа ачык мисал була алалар. Тукайны бөтен зурлыгы белән халыкка кайтару, “Тукайны яңадан “терелтү” өчен барлык дошманнарны фаш итү, аларның һәр төрле пычрак җәтмәләрен ертып ташлау кирәк булды”.[12]

Иҗат принциплары, идея-тематикасы, әдәби геройлары XX йөз башында аермалы булган С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Ф. Әмирхан, Октябрь борылышларыннан соң мөһаҗирлеккә китәргә мәҗбүр булган Г.Исхакый иҗатларына совет әдәби тәнкыйтенең башлангыч дәвере аеруча аяусыз, кешелексез

була.[8] Әдипләрнең иҗатына аларның социаль йөзе, дөньяга карашы, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге ноктасыннан якын киленә. Татар халкының милли азатлыгын, бәйсезлеген яктырткан, мөстәкыйль дәүләтчелек идеясен үткәргән әсәрләр тулаем кире кагыла. Аерым очракларда тәнкыйди фикер әдәби әсәрләрнең, әдәби мирасның художестволылыгына да игътибар итә. Әмма сәнгатьчелек икенчел дәрәҗәдәге, тагылма сыйфат буларак кына карала. Социалистик, интернациональ идеяләр, сыйнфый көрәш мәсьәләләре беренче планда торганда, художестволылык артка чигерелә. Мәсәлән, әдәби тәнкыйть Дәрдемәндне форма ягыннан Баттал, Фәйзиләрдән өстен куя. Ләкин идея-эчтәлек ягыннан, тәнкыйть билгеләгәнчә, ул алардан күпкә түбәнрәк бәяләнә. Шагыйрь "сыйнфый көрәш, динамика, коллективизм, интернационализм" рухыннан аермалы булган гомумкешелек, фәлсәфи мәсьәләләр турында уйлана. Соңгылары сыйныфлар көрәшен гәүдәләндергән әдәбиятта чит, ят кыйммәтләр буларак карала.

Бу елларда әдәби тәнкыйть драматургиягә аеруча "игътибарлы" була. Мондый мөнәсәбәт драма төренең үзенчәлеgenнән, укучыга тәэсир итү көченнән, чорның актуаль мәсьәләләрен тиз тотып алып, тамашачыга тиз арада сәнгатьчә тәкъдим итә алуыннан килә. Шуңа күрә Г.Камал, Ф. Әмирхан, М. Фәйзи, К.Тинчуринннарның драма әсәрләре җентекле тәнкыйть күзлегеннән уздырыла. "Татарның олы драматургы Г. Камал" (1933), "Татар совет драматургиясе югары сыйфат өчен көрәштә үсәргә тиеш" (1933), "Драматургиядә хосусый милекчелек калдыкларына каршы" (1934) һ.б. мәкаләләр шул хакта сөйли. Г.Камалның сатирик планда язылган пьесаларына тәнкыйть уңай мөнәсәбәт белдерә. Ә калганнар мирасыннан, "зоологик милләтчелек, котырынган шовинистлык", "хосусый милекчелекнең зурлыгы, мөкатдәслеге өчен гомер буена көрәшү" тенденцияләрен аерып чыгара.

Димәк, 20 нче еллар башы тәнкыйтендә үк әдәби мирас мәсьәләсе куела. Октябрь инкыйлабы сүз сәнгатен ике чорга – "буржуаз һәм пролетариат" әдәбияты дәверләренә бүлеп

куя. Мондый бүленеш Г.Ибраһимов хезмәтләрендә теоретик яктан эшләнә, пролетариат әдәбиятының төп үзенчәлекләре тәкъдим ителә. Әдәби мирасның, классик әдәбиятнының асыл хасиятләре – миллилек, халыкчылык, дини-әхлакый традицияләр, гомумкешелек кыйммәтләр, мәңгелек темалар "пролетариат әдәбиятының нигез ташлары булган динамика, көрәш, сыйныфчылык, коллективизм, хезмәт һәм интернационализм"[8] кебек сыйфатларга каршы куелалар. 20–30 нчы елларның төрле баскычларында формалашкан социологик, вульгар-социологик, идеологик яки сәяси тәнкыйть әдәби мирасның, иң беренче чиратта, иҗтимагый-сәяси йөзен ачуга йөз тота. Шуңа күрә тәнкыйди фикер әдәби мирасны берьяклы бәяли, аның язмышын хәл итүдә абсолютлаштырылган сыйнфыйлык хәлиткеч рольне уйный.

**Әдәбият**


1 Бурнаш Ф. Тукай шигырьләренә караш//Габдулла Тукай шигырьләре. - Казан:Гажур, 1926.

2 Вәлиди Җ. Әдәби мөсахәбә//Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 5 март.

3 Вәлиди Җ. Аңларга тырыштык, аңлый алмадык//Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 11 март.

4 Гали Г. Академик нәшерләрдә гыйльми нигезләр//Пролетариат әдәбияты өчен көрәшкәндә. - Казан: Татиздат, 1931. - 59-76 б.

5 Ибраһимов Г. Тарихи кыңгыравык өзелде//Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 1 март.

6 Ибраһимов Г. Дүртенче елга кергәндә//Әсәрләр. Сигез томда. 5–т./Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910-1933). - Казан, 1978. - 240-253 б.

7 Ибраһимов Г. Пролетариат әдәбияты турында// Әсәрләр. Сигез томда. 5-т./Әдәбият турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910-1933). - Казан, 1978. - 420-469 б.

8 Нигъмәти Г. Татар совет әдәбияты күтәрелештә: Популяр очерк. – Казан: Татиздат., 1934. – 836.

9 Нигъмәти Г. Татар совет драматургиясе югары сыйфат

өчен көрәштә үсәргә тиеш //Кызыл Татарстан. – 1934. – 26 июль.
10 Сәйфи–Казанлы Ф., Нигъмәти Г., Тинчурин К. Татарның олы драматургы // Кызыл Татарстан. - 1933. - 18 июнь.
11 Туфан Х. Татар совет поэзиясе турында фикерләр // Кызыл Татарстан. - 1934. - 26 июль.
12 Хөсни Ф. Әдәби мирас мәсьәләсе // Кызыл Татарстан. - 1939. - 5 ноябрь.

*Валиев М.Х.*, к.п.н., с.н.с. Института истории АНТ

## ФОРМИРОВАНИЕ ЦЕЛОСТНОЙ ЛИЧНОСТИ В УСЛОВИЯХ ПОЛИЭТНИЧЕСКОГО ОБРАЗОВАНИЯ

Сохранение целостности современного человека становится более актуальным в условиях разнообразия и специализации видов человеческой деятельности, дифференциации общественной жизни по национальному признаку.

В целях целостного развития личности необходимо развивать подрастающее поколение преимущественно на общечеловеческих духовно-нравственных ценностях. В этой связи ведущими направлениями воспитания являются:

а) **формирование отношения к обществу:** воспитание, ориентированное на развитие социальных качеств личности (гражданственности, уважения к закону, социальной активности и ответственности);

б) **человеческих отношений:** (воспитание гуманности уважения прав и свобод личности; достоинства, порядочности);

в) **отношения к культуре** (приобщение к культурным ценностям и достижениям своего и других народов; воспитание духовности, восприятия красоты и гармонии);

г) **отношение к труду и будущей профессии** (воспитание трудолюбия, уважения к трудящемуся человеку любой профессии; сознательный выбор профессии);

д) **личностных отношений** (отношение к семье, детям,

друзьям; формирование совести, чести, порядочности, аксиологических установок) (2; с. 13 - 14).

Национальная школа, обеспечивая преемственность развития национальной культуры, одновременно формирует личность не только как носителя и продолжателя самобытных традиций родного народа, но и (что особенно важно в условиях полиэтнического образования) приобщает подрастающее поколение к общечеловеческим культурным ценностям, прививает учащимся общую культуру. Образовательный процесс строится таким образом, чтобы защищать отдельные культуры в условиях их взаимовосприятия и взаимовлияния.

* В ментальности разных народов много общего. Например:

- любовь к родному краю, к родному языку, гордость за свою национальную историю;
- теплые родственные отношения; почитание старших, благодарное отношение к ним как носителям опыта, знающим жизнь, генеалогию;
- трудолюбие, воспитание детей в труде;
- стремление к знаниям;
- дружеское отношение к другим народам.

Эти ценности являются и общими для любой национальной школы. Усиление внимания к их развитию способствует формированию толерантности и взаимопонимания, проявления уважения к представителю любого народа. Необходимо на ярких примерах из жизни и литературы, на конкретных ситуациях показывать учащимся общее в культурах разных народов (особенно тех народов, которые проживают в наиболее близком социально-экономическом, образовательно-информационном пространстве).

* Одним из важных направлений школы (в том числе и национальной) является подготовка детей к жизни в надэтнической реальности, в которой подрастающее поколение выбирает свой жизненный путь, профессию; находит возможности соотнесения своих личных и общественных интересов; самоутверждается как умственно, нравственно и

физически развитая личность. Это важно для достижения успехов личностью в экономическом, социальном, политическом, духовном пространствах.

* Деятельность национальной школы должна быть адекватна социо-культурным задачам (подготовка личности к жизни; консолидация этносов и отдельных людей; создание условий для наиболее полной самореализации личности и т.п.).

Такой подход позволяет выводить деятельность национальной школы из чисто этнического аспекта на уровень подготовки детей и молодежи к надэтнической реальности с учетом национальности (т.е. языковой и культурной принадлежности) учащихся.

**Литература**:

1. Белозерцев Е. Национальная школа и социальное благополучие // Нар, образование. - 1997. - № 7.

2. Национальная доктрина развития образовательно-воспитательных систем в Республике Татарстан. - Казань, 1998. - 67 с.

3. Харисов Ф.Ф. Интеграция ценностей национальной культуры в систему регионального образования // Педагогическое образование: гуманистические традиции и новаторство: Материалы международной науч.-практ. конф. - Казань: КГПУ, 1999. - С. 25 - 28.

4. Школа и национальное согласие: Материалы межрегиональной конференции. - Казань, 1996. - 156 с.

*Исламов Ф.Ф.*, өлкән фәнни хезмәткәр,
педагогика фәннәре кандидаты

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕГЕ ҺӘМ ПЕДАГОГИК КАРАШЛАРЫ

Каюм Насыйри күренекле тел-әдәбият белгече, тарихчы-этнограф, әдип, журналист кына түгел, ә иҗади эшләүче укытучы-педагог, дәреслекләр авторы да була.

Яшь буынга төпле белем бирү һәм аны дөрес тәрбияләү өлкәсендә камилләшкән мәктәп дәреслекләренең әһәмияте гаять зур. Моны тирән аңлаган К.Насыйри мәктәп-мәдрәсәләр өчен татар телендә арифметика, геометрия, география, тарих, табигать белеме, кулинария, физиология, агрономия һ.б. фәннәр буенча дәреслекләр язды.

К.Насыйри 1855 еллардан алып башта духовное училищеда, аннары духовная семинариядә 1870 елга кадәр 15 ел дәвамында рус балаларына татар теле, ә соңга таба татар балаларына рус телен укыта. Әмма үзе тоткан линиянең дөреслеген тирән аңлаган К.Насыйри яшь буынны укыту-тәрбияләү эшенә бөтен белемен, энергиясен багышлый. Ул практик укытучы гына түгел, бәлки педагог-язучы, нәзари хезмәтләр тудырган оста методист та иде.

"Тәрбиядән максат ашатып, эчертеп, тәнне генә тәрбияләү түгел, бәлки тәнне вә акылны, вә зиһенне тәрбия кылмактыр", - дип тәрбия сүзенең эчтәлеген билгеләгән К.Насыйриның педагогик карашлары бер китапта тупланмаганнар, алар әдипнең төрле әсәрләрендә чәчелеп бирелгәннәр. Галим-педагогның укыту-тәрбия мәсьләләренә караган түбәндәге хезмәтләре мәгълүм: "Балаларга тәгълим бирмәк", "Тәрбия китабы", "Әхлак рисаләсе" китаплары, "Тәрбия", "Мөгайнетдин" мәкаләләре һ.б. Педагогик характерлы фикерләре аның "Фәвакиһел җөләса фил әдәбият" һәм "Кырык бакча" кебек әсәрләрендә шактый киң урын алганнар.

К.Насыйри үзе яшәгән дәвердәге педагог һәм язучылар арасында халыкның рухи үсешендә, яшь буынны төпле белемле итүдә һәм аңа дөрес тәрбия бирүдә туган телнең әһәмиятле роль уйнавын тирән аңлаган галимнәрнең берсе була. Ул бу ягы белән бөек рус педагогы К.Д.Ушинскийга ошый. Россия территориясендә яшәүче дворяннар халык теленә кимсетеп караган, ә чит телләргә табынган вакытта К.Д.Ушинскии рус телен яклап чыккан кебек, К.Насыйри да кайбер укымышлы татар морзаларының татар халык теленә кимсетүле мөнәсәбәтләрен күреп офтанды, татар теленә

гражданлык хокукы бирдерү, туган телдә фәнне үстерү, фәнни-популяр, матур әдәбиятны туган телдә халыкка җиткерү ягында булды.

К.Насыйри укытучы шәхесенең яшь буынны формалаштыруда тоткан урынын ачыклауга киң тукталды. “Әгәр дә мөгаллим вә тәрбияче булсаң, шул рәвешчә тәрбия кыл ки, тәрбия кылынмыш адәмең үлгәнче синең тәрбияң буенча тереклек кыйлырлык булсын”, - дип яза танылган педагог “Тәрбия” исемле хезмәтендә.[19] Бу тәгъбирләрдән К.Насыйриның укытучыдан тирән белем, тәрбия методларын яхшы белүне таләп итүен аңлыйбыз. К.Насыйри укытучы алдында өстәмә түбәндәге таләпләрне дә куя: “Балалар укытырга да бик киң холыклы, вә түземле, чыдамлы кеше кирәк... Акыллы хәлфә булса, армаенча, сукмаенча үгрәтергә тиеш”.

Тәрбия, К.Насыйри аңлатуынча, бала аңын үстерүче, алга җибәрүче, баланы мораль яктан үзгәртүче көчле чара. Моны аның түбәндәге тәгъбирләреннән ачык тоеп була: “Баланың гыйлемгә вә тәрбиягә сәләтле булуы атага карап йөрмидер, ләкин тәрбиягә карап, юаш, сәләтсез балалар да ачылып китәдер”.[20] Тәрбия мәсьәләсенә булган бу дөрес карашка нигезләнеп ул укытучыдан һәм ата-анадан балага яшьтән үк актив тәрбия бирдерү ягында торды. “Баланың иң кыйммәтле гомере үзен-үзе белерлек булып, үзе ашый башлаган вакыттан мәдрәсәдә йөреп, сабак тәмам кылгунчыга чаклы вакытлардыр. Әмә шул вакытлардан баланы яхшы тәрбия кылып тәртипкә вә тәрбиягә төшендермәк лаземдер”, - дип язды К.Насыйри. Педагог балаларның үзләренә киңәш биреп хезмәтләр дә язды. Моны аның педагогик хезмәтләреннән дә, матур әдәбият әсәрләреннән дә ачык тоясың. Проф. Мөхәммәт ага Гайнуллин хаклы: “Каюм Насыйри бер генә минутка да үзенең педагог булуын хәтереннән чыгармады, барлык иҗади хезмәтләрен шуңарга буйсындырып алып барды”.[21] К.Насыйриның педагог һәм методист була-

---

19 К.Насыйри. Сайланма әсәрләр. 2 томда, 2 том. Казан, Т.к.н., 1975, 105-106 бб.

20 Шунда ук, 106 б.

рак эшчәнлеге үл төзегән дәреслекләрдә аеруча киң, ачык чагылды. Шуны хәтердән чыгармаска кирәк, К.Насыйри үзенең педагогик хезмәтләрен, нигездә русның алдынгы фикеренә таянып язды. Аның балалар өчен булган “Буш вакыт” исемле китабының К.Д.Ушинскийдан файдаланып язылуы игътибарга лаеклы.

Шунысы характерлы, К.Насыйри хезмәтләрендә тәрбиянең тулы системасы яктыртылмаган. Әмма аның әсәрләреннән, фәнни хезмәтләреннән тәрбия төрләре (иҗтимагый, акыл, әхлак, патриотик, эстетик, хезмәт һ.б. тәрбия) буенча шактый эшлекле фикерләр табып була.

Балаларны фән нигезләре белән таныштыру аларның төрле яклап формалашуында әһәмиятьле роль уйный. Моны тирән аңлаган К.Насыйри балаларга дөньяви белемнәр бирү һәм алар ярдәмендә яшь буынның акыл үсеше дә йогынты ясау максатында һәркем аңларлык телдә табигать белеме, география, астрономия һәм фәннең башка өлкәләреннән уннарча фәнни-популяр парчалар бирелгән “Буш вакыт” исемле китап бастырып чыгарды. Бу парчалар балаларда фәнни караш тәрбияләү өчен кыйммәтле уку материалы булып хезмәт итәләр.

Фикер иясе кеше акылының җәмгыять тормышында тоткан урынына гаять зур бәя бирә. Акыл белән уйлап эш һәм хәрәкәт итүнең әһәмиятен күп галимнәрнең фикерләренә таянып башкаларга төшендерә. “Нәфеснең тезгене акыл кулындадыр ки, нәфесне яман юлга җибәрмәс. Һәрбер нәрсә күп булган саен бәһасе арзан булыр, кадерсез булыр. Әмма акыл арткан саен бәһасе һәм кадере артыр”, - ди әдип. К.Насыйриның афоризмга әверелгән түбәндәге кыммәтле фикерләре дә бүгенге көндә тәрбияви кыйммәтләрен һичкенә дә югалтмыйлар: “Кеше үзен-үзе таныса, камил акылы шуннан беленер”, “Әгәр берәүгә гыйлем үгрәтергә теләсәң, әүвәл үзеңне-үзең үгрәт”, “Һәр нәрсәнең чиге бар, акылның чиге юк” һ.б.

---

21 К.Насыйри. “Сайланма әсәрләр”, Таткнигоиздат, Казан, 1956, 48 б.

К.Насыйри гомере буе туган халкында туган җиргә мәхәббәт, башка халыкларга карата дуслык тойгысы тәрбияләргә омтылды. Аның бу сыйфаты туган ягына, туган иленә, Идел буе һәм Урал алдында яшәүче күрше чуаш, башкорт, мари һ.б. халыкларга булган җылы мөнәсәбәтендә ачык чагылды. Автор Тау ягы татар Кармыш, чуаш Чәнчас авыллары кешеләренең үзара кунакка йөрешеп, кызлар бирешеп яшәве мисалында халыклар дуслыгының матур үрнәкләрен тасвирлады. "Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыклар әкиятләре белән чагыштыру" дигән хезмәте дә бу күзлектән караганда аеруча әһәмиятле.

К.Насыйри яшь буынга Ватан тешенчәсенә аңлатма бирергә омтылды. Бу төшенчәнең кеше яшәгән төбәк, ил территориясе, тарихы, географиясе, табигате, табигый байлыклары, халыкның туган теле, мәдәнияте, холкы, аның прогрессив традицияләре, гореф-гадәтләре, фольклоры һ.б. белән турыдан туры бәйләнештә булуын төшендерде. Һәрбер яшь кешегә Ватанның үз, якын булырга тиешлеген кисәтте.

К.Насыйриның әхлак тәрбиясенә карата булган фикерләре бүгенге көндә дә үз актуальлекләрен югалтмаганнар. "Кеше бер сүз әйтсә, җиңеллек кылып, тиз үк ачуланып китмәкадерең булмас", - ди галим.

К.Насыйри динне шәхси эш дип санады. Ислам диненең башка диндәге кешеләрне өнәп бетермәвенә ризасызлыгын белдерде, һәр кешенең, милләтенә һәм диненә карамастан, акыл үсешенә хокуклы булуын яклап чыкты. Ул болай дип язды: "Әгәр дә бер адәм белән иптәш булсаң, аның акылына кара, диненә карама. Чөнки аның дине үзенә фәкать, ә акылы үзенә һәм сиңадыр". Шулай итеп ул, кешенең нинди диндә булуына түгел, ә бәлки акыл сәләтенә, әхлакый сыйфатларына югары бәя бирде.

К.Насыйри физик хезмәтнең камилләшкән кеше формалаштыруда әһәмиятле роль уйнавын тирән аңлый, балаларга хезмәт тәрбиясе бирүгә зур игътибар итә Хезмәт турында сүз алып барганда ул халык мәнфәгатен яклаучы булуны күз алдында тота. Моны әдипнең түбәндәге тәгъбирлә-

реннән ачык тоеп була: “Кирәк ниндәен һөнәр булса да, һөнәрнең артыгы юк”.

Физик тәрбия, сәламәтлек, тән тазалыгы мәсьәләләре дә К.Насыйри игътибарыннан читтә калмаган. Ул тәрбиянең бурычы баланы ашату, киендерүгә генә кайтып калмавын дөрес аңлый. Тән тазалыгы һәм сәламәтлеге турында хәстәрлек күрү белән бер үк вакытта кешенең дөньяга карашын, фикерләрен һәм акыл үсешенә бәйләнгән башка төрле сәләтләрен үстерүне алгы планга куя. Тормыш шуны раслый, һәрвакыт таза тәндә таза рух булмаска да мөмкин. Бу уңайдан әйтелгән “Әгәр дә кешенең рухы авыру булса, таза тәннән нинди файда бар” дигән тәгъбирләре бүген дә актуаль яңгырыйлар. Әдипнең бу тәгъбирләре кешегә хас булган гүзәл сыйфатлар, намуслылык, рухи байлык аның физик тазалыгыннан әһәмиятлерәк, кыйммәтрәк, дигән мәгънәне аңлата. Фикер иясе яшь буынның физик яктан гармоник үсеше өчен нормаль туклану, саф һавада булу зарури дип саный, әмма шул ук вакытта баланың бөтен, теләгән дә үтәргә ярамавын, мондый тәрбиянең балаларны бозуга китерүе турында кисәтә.

К.Насыйри физик тәрбиянең нигезе итеп хезмәтне исәпләгән. Ул бөтен гомере буена акыл хезмәте белән физик хезмәтне бергә алып барырга омтылган. Педагог эстетик тәрбия мәсьәләләренә дә игътибар итмичә калмаган. Хезмәтләрендә, бигрәк тә “Фәвакиһел җөләса фил әдәбият” дигән күләмле әсәрендә музыканың һәм җырның кеше тормышында әһәмиятле роль уйнавын ачыклый, яшьләрне сәнгатьнең бу төрләре белән таныштыруны максат итеп куя. Галим үз фикерләрен раслау өчен, хезмәтләрендә күп кенә дәлилләр дә китерә, җырның, музыканың күңелгә шатлык, хәрәкәткә батырлык бирүе хакында әйтә.

К.Насыйри – патриот, халыклар дуслыгы җырчысы иде. Аның бөтен тормыш юлы, иҗаты шул турыда сөйли. Әдипнең туган җир, Ватан, туган тел, халыклар дуслыгы турындагы фикерләрен, гүзәл эшчәнлеген яшь буынны патриотик, халыклар дуслыгы рухында тәрбияләү максатында киң

файдаланырга мөмкин. Бөек шәхес безнең арабызда юк. Әмма аның бай педагогик мирасы бүгенге көндә дә яшьләргә гуманлылык тәрбиясе бирү эшендә зур булышлык күрсәтә.

*Гибатдинов М.М.*, аспирант

## Проблема государственности в школьном курсе истории татарского народа и Татарстана

Для истории любого народа процесс становления и развития его государственности является важным, ключевым моментом. Однако сведения исторического исследования только к развитию государства существенно сужает его рамки. До недавнего времени подобным недостатком страдала Истории России, СССР, а вслед за ними и история ТАССР. Современные историки стремятся больше внимания уделять изучению развития духовной и материальной культуры, мировоззрения и образа жизни людей. К сожалению, большинство нынешних школьных учебников ограничиваются изложением политической и экономической истории государства, особенно это относится к учебникам по Истории России.

С учебниками по истории Татарстана положение несколько иное. Их авторы, являясь в основном археологами и историками культуры много внимания уделяют этим аспектам истории, но и история государственности занимает свое значительное место.

Как известно, государственность – особый признак, которым отмечено историческое развитие стран, наций, союзов племен и т.п. образований, сумевших создать собственное государство или восстановивших утерянное в силу разных причин свое государство. В истории татарского народа чередовались периоды существования нескольких татарских государственных образований, их объединения в рамках одной мощной империи, с периодами практически полного разрушения, потери своего государства и нового его возрождения. Таким образом, проблема государственности

является в истории татарского народа особенно важной и актуальной на всем ее протяжении. В этой связи и в преподавании курса Истории татарского народа и Татарстана возникает ряд проблем.

Какие образования можно считать “государствами татарского народа” и включать в курс изучения истории татарского народа в средней школе? Какова преемственность древних и более поздних государств в институтах, специфических формах государственной, политической организации общества, политических отношениях, структурах власти? В чем заключается особенности татарской государственности, как синтеза государственных традиций оседлого и кочевого мира?

Рассмотрим как решаются в курсе истории татарского народа и Татарстана некоторые из этих проблем.

Все авторы существующих учебников единодушно причисляют к государствам татарского народа Волжскую Булгарию, казанское ханство и Золотую Орду. Другие тапы развития татарской государственности разные авторы определяют исходя из собственного видения проблем этногенеза татарского народа. Часть ограничивается преимущественно булгарским и монгольским компонентами[22], другие отмечают те из тюркских государств, которые оказывали непосредственное влияние на развитие народов живших в Волго-Камье, Нижней Волге, Причерноморских степях[23]. Существует и другая точка зрения. К татарским государствам относятся в той или иной мере все государственные образования, в рамках которых развивались народы и племена впоследствии участвовавшие в процессе этногенеза татарского

---

22 Мифтахов З.З, Мухамадеева Ф.Ш. история Татарстана и татарского народа: Учебник для средних общеобразовательных школ, гимназий и лицеев. Ч.I – Казань: Магариф, 1996.

23 Давлетшин Г.М., Хузин Ф.Ш., Измайлов И.Л. рассказы по истории Татарстана. – Казань: Магариф, 1994.

народа и отдельных его этнических групп[24].

Многие вопросы древней и средневековой истории татарского народа находятся еще в стадии изучения и осмысления. Особое внимание к этим проблемам истории татар является не только следствием многолетнего запрета и ограничения на изучение ее ранних периодов, но и возрождением существовавшей прежде традиции. В программе медресе Мухаммадия за 1913-1914 уч.год большое место уделено изучению истории тюркских племен, в том числе и древних татар, гуннов, хазар и половцев[25]. Появились и новые археологические находки изменившие взгляды на роль Тюркского каганата в формировании татарского народа.

Господствующий в отечественных учебниках истории европоцентризм приводит к тому, что история древних и средневековых тюрков если и изучается, то крайне скудно с большими искажениями. В основном освещаются вопросы завоевательной политики кочевников, которые "не пускали земледельцев в степь, и плодородная полоса в 1000 км. Была всего лишь огромным пастбищем". В учебнике по Истории Отечества изданном в 1996 г. только одним предложением упоминаются булгары: "Эти булгары были одними из предков татар Среднего Поволжья и чувашей"[26]. О государственности нет и речи. В 1999г. положение несколько меняется. В "Российской истории" отдано 7 стр. на §2. Народы и государства (выделено нами. – Г.М.) на просторах нашей страны в 1 тыс. н.э. страницы 25-26 посвящены хазарскому каганату и Волжской Булгарии – "новым государствам Восточной Европы". Отдельно рассматривается и евразий-

---

24 Фахрутдинов Р.Г. история татарского народа и Татарстана: Учебник для средних общеобразовательных школ, гимназий и лицеев. Ч.I – Казань: Магариф, 1995.

25 "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе. – Казан: Мәгариф, 1998; Вәлиди Әхмәд – Зәки кыскача төрек -татар тарихы. - Казан: Татар.кит.нәшр., 1992.

26 Преображенский А А., Рыбаков Б.А. История Отечества: Учеб.для 6-7 кл. М.: Просвещение, 1996.

ская степь в начале Средневековья. Здесь авторы говорят о возникновении воинственных ранних государств – “кочевых империй”. В рамках которых народы обменивались навыками ремесла, земледелия, скотоводства. Была создана тюркская руническая письменность. Особо отмечается, что на территории нашей страны “многие народы находили свой путь дальнейшего развития к цивилизации”[27]. По новому освящены и распад Золотой Орды и отношения Москвы и татарских ханств. Пособия подобные этому очень редки даже среди новых изданий, и еще не получили распространения в наших школах.

Учебники по истории татарского народа дают шанс исправить это положение и заполнить пробел. Однако, необходимо найти ту четкую грань, которая отделяет историю татарского народа от превращения в историю тюркских народов.

Традиционно, в науке более тщательно изучены Волжская Булгария и Казанское ханство. И в учебниках им уделяется основное внимание, основательно рассматривается и история Джучиева Улуса. Уделяется некоторое внимание и особенностям и специфике кочевого образа жизни и кочевого государства. Но, в целом феномен кочевой, степной цивилизации остается для учеников по прежнему загадкой. Попытка приподнять эту завесу предпринята в учебнике Р.Г.Фахрутдинова.

К сожалению средневековый и древний периоды истории этих народов изучены недостаточно. Возможно, со временем историческая наука сможет получить более определенные сведения о характере этих древних государств.

Не следует упускать из вида и не тюркские компоненты татарской государственности. Все государства начиная с Тюркского каганата до Республики Татарстан, которые мы называем “татарскими” являлись в большей или меньшей степени многонациональными, в их орбиту входили самые разные народы, и не только тюркские.

---

27 Данилов А.А., Данилов Д.Д. Российская история с древнейших времен до нач. XVI в. М.1999.

Стремлению “татаризировать” общетюркскую история и в методическом и методологическом плане целесообразно было бы противопоставить более четкое разграничение общетюркского и татарского периодов, государственного и догосударственного периодов. Необходимо больше внимания уделять изучению особенностей степного способа жизни и хозяйствования, особенностям, специфике и устройству кочевого государства и его влиянию и взаимодействию с оседлыми соседями. При изучении истории становления государственности татарского народа крайне необходимо как можно более полно использовать те немногочисленные источники, которые у нас имеются. Работа с первоисточникам, хрестоматией, с подлинным документом может облегчить решения многих проблем.

Первые шаги в этом направлении сделали авторы I и IV частей учебника по истории татарского народа и татарстана. Однако создание хрестоматии по данному курсу средней школы остается одной из важнейших проблем и требует своего решения.

В своем современном понимании государственность не только показатель уровня развития общества, не только наличие определенных политических институтов и структур. Государственность это и “идеология, общестенная, политическая и культурная ориентация, направляющая страну на развитие государства, его защиту, совершенствование политической организации общества”[28].

Применительно к истории татарского народа ее можно было бы определить как направленную на восстановление утеренной государственности, воспоминания и стремление к которой не исчезали у народа никогда. Целесообразным представляется при написании части III учебника и переиздании ч.II уделять больше внимания именно этому аспекту, перенести акценты с истории края на историю народа.

---

28 Политология: Энциклопедический словарь. - М.1993.

Сборник научных статей

МИЛЛИ МӘКТӘП ҺӘМ УКЫТУНЫҢ МӨҺИМ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

НАЦИОНАЛЬНАЯ ШКОЛА И АКТУАЛЬНЫЕ ПРОБЛЕМЫ ОБУЧЕНИЯ

Редоктор М.Х. Валиева
Компьютерная верстка Л.Р. Гимрановой

Издательство «Мастер Лайн»